Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

14 .11. 2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пункты территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.

2. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Киров урамындагы 3 нче йорттан 9 нчы йортка кадәрге Чуваш Чурапаны торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш, ком сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, салу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Җитәкче И.М.Шәмсетдинов